ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
14.09.2023

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
№ 2797

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 13 августындагы 1909 номерлы карары белән ( 2022 елның 21 мартындагы 596 номерлы карарындагы үзгәрешләр белән) расланган «Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты»на үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм «Россия Федерациясендә тимер юл транспорты турында» Федераль законның 16 статьясындагы 2 пунктының икенче абзацының үз көчен югалтуын тану хакында» 2022 елның 29 декабрендәге 612-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, , Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 13 августындагы 1909 номерлы карары белән ( 2022 елның 21 мартындагы 596 номерлы карарындагы үзгәрешләр белән) расланган «Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты»на(алга таба - административ регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.административ регламентның 2.5.1 пунктындагы 4 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;

1.2.административ регламентның 2.5.1 пунктындагы 6 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;

1.3.административ регламентның 2.5.1 пунктының 8 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы З.Ф. Хәбибуллин